МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 22.12.2021 Казан ш. № 02-133

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.09.2018 ел, № 02-110 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.09.2018 ел, № 02-110 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләрне (кушымта итеп бирелә) (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.12.2018 ел, № 02-152, 15.03.2019 ел, № 02-31, 17.10.2019 ел, № 02-108, 04.12.2019 ел, № 02-129, 24.12.2019 ел, № 02-139, 27.03.2020 ел, № 02-35, 28.07.2020 ел, № 02-84, 14.12.2020 ел, № 02-133, 21.12.2020 ел, № 02-137, 01.07.2021 ел, № 02-55, 22.10.2021 ел, № 02-100 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
22 декабрь 2021 ел,
№ 02-133 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.09.2018 ел, № 02-110 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр

1. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре» 2 пунктында:

а) «2025 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасы» 2.1.пунктчасында:

«01 2 09 00000 «Башка авырулардан интегүче сырхауларга медицина ярдәме күрсәтү системасын камилләштерү. Дәвалап җиткерүне һәм реабилитацияне оештыру» төп чарасы» максатчан статьясында «- 5845F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, яңа коронавирус инфекциясен диагностикалауны хәл итүче медицина оешмаларының лабораторияләрен тәэмин итү (яңача тәэмин итү) буенча чараларны финанс ягыннан тәэмин итү» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 5845F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, нуклеин кислоталары амплификациясе ысуллары белән яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) этиологик диагностикалауны хәл кылучы медицина оешмалары лабораторияләрен медицина эшләнмәләре белән тәэмин итү (яңача тәэмин итү) буенча чараларны финанс ягыннан тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча нуклеин кислоталары амплификациясе ысуллары белән яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) этиологик диагностикалауны хәл кылучы медицина оешмалары лабораторияләрен медицина эшләнмәләре белән тәэмин итү (яңача тәэмин итү) буенча чараларны финанс ягыннан тәэмин итүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына бюджетларга тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49001 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

«01 2 N1 00000 «Беренчел медицина-санитария ярдәмен күрсәтү системасын үстерү» федераль проекты» максатчан статьясында «- 55540 Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәте белән тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 55540 Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәтләрен сатып алуларны тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча чагылдырыла:

- медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәтләрен сатып алуларны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирүгә федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәтләрен сатып алуларны тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25554 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла

- медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәтләрен сатып алуларны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чыгымнары.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фондлары бюджетына кире кайтарылмый торган башка акчалар» 000 2 02 90029 09 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«01 7 03 00000 «Медицина хезмәткәрләренең аерым категорияләренә социаль ярдәм» төп чарасы» максатчан статьясында «- R1380 Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр түләнелә торган компенсация түләүләренә финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- R1380 Авыл торак пунктларына, яки эшчеләр бистәләренә яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә халык саны 50 мең кешегә кадәрге шәһәрләргә эшләргә кайткан (күченеп кайткан) медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, шулай ук фельдшерлык һәм фельдшер-акушерлык пунктларының медицина шәфкать туташларына) бер тапкыр түләнелә торган компенсация түләүләренә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча авыл торак пунктларына, яки эшчеләр бистәләренә яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә халык саны 50 мең кешегә кадәрге шәһәрләргә эшләргә кайткан (күченеп кайткан) медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, шулай ук фельдшерлык һәм фельдшер-акушерлык пунктларының медицина шәфкать туташларына) бер тапкыр түләнелә торган компенсация түләүләренә федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан

Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителәә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Авыл торак пунктларына, яки эшчеләр бистәләренә яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә халык саны 50 мең кешегә кадәрге шәһәрләргә эшләргә кайткан (күченеп кайткан) медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, шулай ук фельдшерлык һәм фельдшер-акушерлык пунктларының медицина шәфкать туташларына) бер тапкыр түләнелә торган компенсация түләүләренә бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25138 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

«01 Б 01 00000 «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру системасын камилләштерү» төп чарасы» максатчан статьясында «- 5849F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясен йоктырган һәм (яки) инфекция йоктыруга шик төшкән затларга медицина ярдәме күрсәтүне финанс ягыннан өстәмә тәэмин итү» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 5849F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе буенча иминиятләштерелгән затларга, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) йоктырган һәм (яки) инфекция йоктыруга шик төшкән затларга медицина ярдәме күрсәтүне финанс ягыннан өстәмә тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча чагылдырыла:

- мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе буенча иминиятләштерелгән затларга, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) йоктырган һәм (яки) инфекция йоктыруга шик төшкән затларга медицина ярдәме күрсәтүне финанс ягыннан өстәмә тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фондына бюджетара трансфертлар бирүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49001 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла;

- мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе буенча иминиятләштерелгән затларга, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) йоктырган һәм (яки) инфекция йоктыруга шик төшкән затларга медицина ярдәме күрсәтүне финанс ягыннан өстәмә тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чыгымнары.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе буенча иминиятләштерелгән затларга, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) йоктырган һәм (яки) инфекция йоктыруга шик төшкән затларга медицина ярдәме күрсәтүне финанс ягыннан өстәмә тәэмин итүгә мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 55849 09 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

б) «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» дәүләт программасы» 2.2. пунктчасында «02 К Е1 00000 «Заманча мәктәп» федераль проекты» максатчан статьясында «- 55200 Россия Федерациясе субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыруга ярдәм итү буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

«- 55200 Гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру буенча чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру буенча чараларны тормышка ашыруга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25520 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

в) «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы» 2.3. пунктчасында:

«03 1 01 00000 «Федераль һәм республика законнарында билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү»«төп чарасы» максатчан статьясында:

«- 51980 Россия Федерациясе Пенсия фонды средстволары хисабына, Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт Геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль ярдәм» чыгымнар юнәлешенә түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт Геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль ярдәмгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45198 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«- 52520 Россия Федерациясе Пенсия фонды хисабына, Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына һәм Дан орденының тулы кавалерларына социаль ярдәм» чыгымнар юнәлешенә түбәндәге эчтәлектәге өченче абзацны өстәргә:

«Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына һәм Дан орденының тулы кавалерларына социаль ярдәмгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45252 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«03 3 01 00000 «Халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү» төп чарасы» максатчан статьясында «- 5837F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, аеруча мөһим эшләр башкарган өчен, аерым хезмәт шартлары һәм өстәмә нагрузка өчен үзләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелгән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының хезмәткәрләренә чираттагы ялларына һәм файдаланылмыйча калган яллары өчен компенсацияләр түләүгә, шул исәптән әлеге максатларга элегрәк хәл ителгән чыгымнарга компенсация түләүгә бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү» чыгымнар юнәлеше» төп чарасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 5837F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, 2020 елда Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә, аерым хезмәт шартлары һәм өстәмә нагрузка өчен үзләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелгән стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар булмаган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында булдырылган стационар бүлекләр хезмәткәрләренә чираттагы ялларга түләүне һәм файдаланылмыйча калган чираттагы ялларга түләүне, шул исәптән әлеге максатларга Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан элегрәк хәл ителгән чыгымнарны компенсацияләү максатыннан, финанс ягыннан тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 2020 елда Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә, аерым хезмәт шартлары һәм өстәмә нагрузка өчен үзләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелгән стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар булмаган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында булдырылган стационар бүлекләр хезмәткәрләренә чираттагы ялларга түләүне һәм файдаланылмыйча калган чираттагы ялларга түләүне, шул исәптән әлеге максатларга Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан элегрәк хәл ителгән чыгымнарны компенсацияләү максатыннан, финанс ягыннан тәэмин итүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49001 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

г) «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасы икътисади үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы» 2.11. пунктчасында:

«11 8 01 00000 «Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын булдыру» төп чарасы» максатчан статьясында «- 60680 «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисади зонасы» индустриаль паркы («Алабуга-2» индустриаль паркы) инфраструктурасы объектларын булдыруның, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләүнең барышына средстволарның максатчан тотылуы максатында төзелеш күзәтчелеге» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 60680 Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү буенча төзелеш-монтаж эшләренә техник аудит үткәрү»;

«11 8 02 00000 «Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү» төп чарасы» максатчан статьясы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 8 02 00000 «Җирле үзидарә органнарына кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү» төп чарасы;

беренче абзацта «түбәндәге юнәлешләргә» дигән сүзләрне «түбәндәге юнәлешкә» дигән сүзләргә алыштырырга;

«- 60870 Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплаугасубсидияләр» чыгымнар юнәлешен төшереп калдырырга;

д) «2013 – 2025 Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясен, чималын һәм азык-төлекне җайга салу» дәүләт программасы» 2.14. пунктчасында:

«14 1 05 00000 «Туфракның уңдырышлылыгын арттыру һәм файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы биләмәләрен авыл хуҗалыгына әйләнешкә кертү» төп чарасы» максатчан статьясында

түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- R3680 Ашлык культураларын җитештерү һәм сату буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча ашлык культураларын җитештерүчеләрнең ашлык культураларын җитештерү һәм сату буенча чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Ашлык культураларын җитештерүчеләрнең ашлык культураларын җитештерү һәм сату буенча чыгымнарының бер өлешен каплауга Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатыннан чыгып, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара

трансфертлар» 000 2 02 45368 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«- R5080 Үсемлекчелек һәм терлекчелекнең кайбер кече тармакларына ярдәм итүгә, шулай ук авыл хуҗалыгын иминиятләштерүгә финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- R5080 Үсемлекчелек һәм терлекчелекнең кайбер кече тармакларына ярдәм итүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча үсемлекчелек һәм терлекчелекнең кайбер кече тармаклары буенча авыл хуҗалыгы производствосына ярдәм итүгә федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Үсемлекчелек һәм терлекчелекнең кайбер кече тармаклары буенча авыл хуҗалыгы производствосына ярдәм итүгә бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25508 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

«14 2 01 00000 «Терлекчелекнең сөтчелек тармагын үстерү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«-5669F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, сөт өчен мөгезле эре терлек үрчетүне һәм (яки) тотуны хәл кылучы җитештерүчеләргә сөт өчен мөгезле эре терлек үрчетү һәм (яки) тоту өчен терлек азыгы сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сөт өчен мөгезле эре терлек үрчетүне һәм (яки) тотуны хәл кылучы җитештерүчеләргә сөт өчен мөгезле эре терлек үрчетү һәм (яки) тоту өчен терлек азыгы сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49001 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«14 2 09 00000 «Хайваннар авыруларын кисәтү һәм халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан саклау» төп чарасы» максатчан статьясында «- 25360 Хайваннар авыруларын кисәтү һәм юкка чыгару, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән саклау буенча чаралар үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 25360 Хайваннар авыруларын кисәтү һәм юкка чыгару, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән саклау буенча, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә чаралар үткәрүне тормышка ашыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча хайваннар авыруларын кисәтү һәм юкка чыгару, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән саклау буенча, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә чаралар үткәрүне тормышка ашыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга җирле бюджетларга субвенцияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең җирле бюджетларга керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларына тапшырыла торган вәкаләтләрне үтәүгә җирле бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 30024 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

Шулай ук чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр хисабына хәл ителә торган җирле бюджетлар чыгымнары чагылдырыла.»;

«14 6 02 00000 «Дәүләт программасын тормышка ашыруны кадрлар белән тәэмин итү» төп чарасы» максатчан статьясында «- 60060 Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме буенча чаралар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 60060 Агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме буенча чаралар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме буенча чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«14 6 06 00000 «Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарны компенсацияләү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешләрен өстәргә:

«- R472F Шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарны каплау буенча финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга бюджетларга тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45472 00 0000 150 к еремнәр төренең тиешле коды буенча чагылдырыла.

- R655F Резерв фонды фонды средстволары хисабына, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, сөтчелек юнәлешендә терлекчелек комплексларын (сөтчелек фермаларын), үсемлекчелек тармагында саклагычлар һәм селекция-орлыкчылык үзәкләрен файдалануга тапшыру максатыннан чыгып, агросәнәгать комплексы объектларын булдыруга һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сөтчелек юнәлешендә терлекчелек комплексларын (сөтчелек фермаларын), үсемлекчелек тармагында саклагычлар һәм селекция-орлыкчылык үзәкләрен файдалануга тапшыру максатыннан чыгып, агросәнәгать комплексы объектларын булдыруга һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Бюджетларга тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49999 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле коды буенча чагылдырыла.»;

«14 6 T2 00000 «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты» максатчан статьясында «- 52510 Илкүләм аккредитация системасында ветеринария лабораторияләренең аккредитация алулары өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 52510 Илкүләм аккредитация системасында ветеринария лабораторияләре аккредитацияләүгә дәүләт ярдәменә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча илкүләм аккредитация системасында ветеринария лабораторияләренең аккредитация алулары өчен дәүләт ярдәменә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Илкүләм аккредитация системасында ветеринария лабораторияләренең аккредитация алулары өчен дәүләт ярдәменә бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25251 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

е) «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.22. пунктчасында «23 0 01 00000 «Автомобиль транспортының әйләнә-тирә мохиткә һәм халыкның сәламәтлегенә тискәре йогынтысын тотрыклы киметүне тәэмин итү һәм автотранспорт чараларында ташуларны хәл итүнең иң зур икътисади нәтиҗәсенә ирешү» төп чарасы» максатчан статьясында «- R2610 Мотор ягулыгы сыйфатында кысылган табигый газ тутыру инфраструктурасын төзү һәм үстерү һәм мотор

ягулыгы сыйфатында табигый газдан файдалану өчен автомобиль техникасын яңадан җиһазлау буенча проектларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- R2610 Газ-мотор ягулыгын үстерү буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча газ-мотор ягулыгын үстерү буенча чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Газ-мотор ягулыгы базарын үстерү буенча чараларны тормышка ашыруга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25261 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

ж) «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасы» 2.23. пунктчасында «24 1 01 00000 «Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә юстиция өлкәсендәге сәясәтне хәл итү» төп чарасы» дәүләт программасында «- 51410 Федераль бюджет средстволары хисабына, Дәүләт Думасы депутатлары һәм аларның ярдәмчеләре эшчәнлеген тәэмин итү» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Россия Федерациясе сенаторы статусы һәм Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты статусы турында» 8 май, 1994 ел, № 3-ФЗ Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатларының һәм аларның ярдәмчеләренең сайлау округларындагы эшчәнлеген матди яктан тәэмин итүгә бәйле рәвештә башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә килеп чыккан өстәмә чыгымнарны компенсацияләүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

з) «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы» $2.30^{1}$ пунктчасында «37 К 00 00000 «Татарстан республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» кече программасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 54450 «Чаңгы һәм биатлон буенча күнегүләр һәм ярышлар үткәрү өчен спорт комплексы» капиталь төзелеш объектына капитал салуларга хәл ителгән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын каплау

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Чаңгы һәм биатлон буенча күнегүләр һәм ярышлар үткәрү өчен спорт комплексы» капиталь төзелеш объектына капитал салуларга хәл ителгән чыгымнарны каплау максатыннан, Татарстан Республикасы бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45445 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

и) «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасы» 2.30[2] пунктчасында «38 3 E8 00000 «Социаль активлык» федераль проекты» максатчан статьясында «- 54120 Волонтерлыкка ярдәм итү буенча «Изге эшләр төбәге» Бөтенроссия иң яхшы төбәк практикалары конкурсын үткәрүгә финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 54120 Волонтерлыкка ярдәм итү буенча «Изге эшләр төбәге» Бөтенроссия иң яхшы төбәк практикаларына ярдәм итү һәм ихтыярилыкны (волонтерлыкны) үстерү еллык конкурсын үткәрү йомгаклары буенча ихтыярилыкка (волонтерлыкка) ярдәм итү практикаларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча волонтерлыкка ярдәм итү буенча «Изге эшләр төбәге» Бөтенроссия иң яхшы төбәк практикаларына ярдәм итү һәм ихтыярилыкны (волонтерлыкны) үстерү еллык конкурсын үткәрү йомгаклары буенча ихтыярилыкка (волонтерлыкка) ярдәм итү практикаларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Изге эшләр төбәге» Бөтенроссия иң яхшы төбәк практикаларына ярдәм итү конкурсын үткәрү йомгаклары буенча Россия Федерациясе субъектларында тормышка ашырыла торган волонтерлыкка ярдәм итү һәм үстерү практикаларын тормышка ашыруга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25412 00 0000 150 к еремнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

к) «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ тутыру компрессор станцияләрен төзү» дәүләт программасы» 2.30[3] пунктчасында «36 0 01 00000 «Автомобильләргә яңа газ тутыру компрессор станцияләрен төзү һәм файдалануга тапшыру» төп чарасы» максатчан статьясында «- R2610 Кысылган табигый газ тутыру инфраструктурасын төзү һәм үстерү һәм мотор ягулыгы сыйфатында табигый газдан файдалану өчен автомобиль техникасын яңадан җиһазлау буенча проектларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- R2610 Газ мотор ягулыгы базарын үстерү буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча газ мотор ягулыгы базарын үстерү буенча чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Газ мотор ягулыгы базарын үстерү буенча ч араларга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25261 00 0000 150 к еермнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

л) «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджеты чыгымнарының программаларга кертелмәгән юнәлешләре» 2.31 пунктчасында «99 0 00 00000 Чыгымнарның программаларга кертелмәгән юнәлешләре» максатчан статьясында:

«- 51420 Федераль бюджет средстволары хисабына, Россия Федерациясе сенаторлары һәм аларның ярдәмчеләре эшчәнлеген тәэмин итү» чыгымнар юнәлешенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Россия Федерациясе сенаторы статусы һәм Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты статусы турында» 8 май, 1994 ел, № 3-ФЗ Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе сенаторларының һәм аларның ярдәмчеләренең Россия Федерациясе субъектларындагы эшчәнлеген матди яктан тәэмин итүгә бәйле рәвештә башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә килеп чыккан өстәмә чыгымнарны компенсацияләүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла «.»;

«- 72370 «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 27 декабрь, 2004 ел, № 69-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, торакка хокукны тормышка ашыручы гаиләләргә һәр бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү максатыннан, махсус оешма булып торучы коммерциясез оешмага субсидияләр» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 72370 «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 27 декабрь, 2004 ел, № 69-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, торакка хокукны тормышка ашыручы гаиләләргә һәр бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү максатыннан, махсус оешма булып торучы коммерциясез оешмага субсидияләр»;

«- 95010 Күп фатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь төзекләндерү үткәрүгә Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 95010 Күп фатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь төзекләндерү үткәрүгә, Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар»;

«- R2990 Дәүләт милкендәге хәрби каберлекләрне төзекләндерү һәм торгызу буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- R2990 «2019 – 2024 елларга, Ватанны саклауда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү» федераль максатчан программасын тормышка ашыруга бәйле чараларны хәл кылуга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «2019 – 2024 елларга, Ватанны саклауда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү» федераль максатчан программасын

тормышка ашыруга бәйле чараларны хәл кылуга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «2019 – 2024 елларга, Ватанны саклауда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү» федераль максатчан программасын тормышка ашыруга бәйле Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25299 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.».

2. 2 кушымтада:

а) юлны

| | |
|---|---|
| «01 2 09 5845F | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, яңа коронавирус инфекциясен диагностикалауны хәл итүче медицина оешмаларының лабораторияләрен тәэмин итү (яңача тәэмин итү) буенча чараларны финанс ягыннан тәэмин итү» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «01 2 09 5845F | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, нуклеин кислоталары амплификациясе ысуллары белән яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) этиологик диагностикалауны хәл кылучы медицина оешмалары лабораторияләрен медицина эшләнмәләре белән тәэмин итү (яңача тәэмин итү) буенча чараларны финанс ягыннан тәэмин итү»; |

б) юлны

| | |
|---|---|
| «01 2 N1 55540 | Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәте белән тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «01 2 N1 55540 | Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәтләрен сатып алуларны тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар»; |

в) юлны

| | |
|---|---|
| «01 7 03 R1380 | Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр түләнелә торган компенсация түләүләренә финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «01 7 03 R1380 | Авыл торак пунктларына, яки эшчеләр бистәләренә яисә шәһәр тибындагы бистәләргә, яисә халык саны 50 мең кешегә кадәрге шәһәрләргә эшләргә кайткан (күченеп кайткан) медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, шулай ук фельдшерлык һәм фельдшер-акушерлык пунктларының медицина шәфкать туташларына) бер тапкыр түләнелә торган компенсация түләүләренә финанслашыла торган чыгымнар»; |

г) юлны

«01 Б 01 5849F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясен йоктырган һәм (яки) инфекция йоктыруга шик төшкән затларга медицина ярдәме күрсәтүне финанс ягыннан өстәмә тәэмин итү»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«01 Б 01 5849F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе буенча иминиятләштерелгән затларга, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) йоктырган һәм (яки) инфекция йоктыруга шик төшкән затларга медицина ярдәме күрсәтүне финанс ягыннан өстәмә тәэмин итү»;

д) юлны

«02 К Е1 55200 Россия Федерациясе субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыруга ярдәм итү буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«02 К Е1 55200 Гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыруга ярдәм итү буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар»;

е) юлны

«03 3 01 5837F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, аеруча мөһим эшләр башкарган өчен, аерым хезмәт шартлары һәм өстәмә нагрузка өчен үзләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелгән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының хезмәткәрләренә чираттагы елларына һәм файдаланылмыйча калган еллары өчен компенсацияләр түләүгә, шул исәптән әлеге максатларга элегрәк хәл ителгән чыгымнарга компенсация түләүгә бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«03 3 01 5837F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, 2020 елда Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә, аерым хезмәт шартлары һәм өстәмә нагрузка өчен үзләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелгән стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар булмаган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында булдырылган стационар бүлекләр хезмәткәрләренә чираттагы елларга түләүне һәм файдаланылмыйча калган чираттагы елларга түләүне, шул исәптән әлеге максатларга Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан элегрәк хәл ителгән чыгымнарны компенсацияләү максатыннан, финанс ягыннан тәэмин итү»;

ж) юлны

«11 8 01 60680 «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисади зонасы» индустриаль паркы («Алабуга-2» индустриаль паркы) инфраструктурасы объектларын булдыруның, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләүнең

| | |
|---|---|
| | барышына средстволарның максатчан тотылуы максатында төзелеш күзәтчелеге)» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «11 8 01 60680 | Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү буенча төзелеш-монтаж эшләренә техник аудит үткәрү»; |

з) юлны

| | |
|---|---|
| «11 8 02 00000 | «Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү төп чарасы» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «11 8 02 00000 | Җирле үзидарә органнарына кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү» төп чарасы»; |

и) юлны

| | |
|---|---|
| «11 8 02 60870 | Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр» |

төшереп калдырырга;

к) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «14 1 05 R3580 | Ашлык культураларын җитештерүчеләргә ашлык культураларын җитештерү һәм сату чыгымнарының бер өлешен каплауга финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «14 1 05 R3680 | Ашлык культураларын җитештерүчеләргә ашлык культураларын җитештерү һәм сату чыгымнарының бер өлешен каплау буенча финанслашыла торган чыгымнар»; |

л) юлны

| | |
|---|---|
| «14 1 05 R5080 | Үсемлекчелек һәм терлекчелекнең кайбер кече тармакларына ярдәм итүгә, шулай ук авыл хуҗалыгын иминиятләштерүгә финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «14 1 05 R5080 | Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә үсемлекчелек һәм терлекчелекнең кайбер кече тармакларына ярдәм итүгә финанслашыла торган чыгымнар»; |

м) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «14 2 01 00000 | «Терлекчелекнең сөтчелек тармагын үстерү» төп чарасы |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

«14 2 01 5669F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, сөт өчен мөгезле эре терлек үрчетүне һәм (яки) тотуны хәл кылучы җитештерүчеләргә сөт өчен мөгезле эре терлек үрчетү һәм (яки) тоту өчен терлек азыгы сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр»;

н) юлны

«14 2 09 25360 Хайваннар авыруларын кисәтү һәм юкка чыгару, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән саклау буенча чаралар үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 2 09 25360 Хайваннар авыруларын кисәтү һәм юкка чыгару, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән саклау буенча, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә чаралар үткәрүне тормышка ашыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру»;

о) юлны

«14 6 02 60060 Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме буенча чаралар»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 6 02 60060 Агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме буенча чаралар»;

п) юлдан соң

«14 6 06 R4720 Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарны компенсацияләү»

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

«14 6 06 R472F Шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарны каплау буенча финанслашыла торган чыгымнар

14 6 06 R655F Резерв фонды фонды средстволары хисабына, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, сөтчелек юнәлешендә терлекчелек комплексларын (сөтчелек фермаларын), үсемлекчелек тармагында саклагычлар һәм селекция-орлыкчылык үзәкләрен файдалануга тапшыру максатыннан чыгып, агросәнәгать комплексы объектларын булдыруга һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча финанслашыла торган чыгымнар»;

р) юлны

«14 6 T2 52510 Илкүләм аккредитация системасында ветеринария лабораторияләренең аккредитация алулары өчен дәүләт ярдәменә финанслашыла торган чыгымнар»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «14 6 Т2 52510 | Илкүләм аккредитация системасында ветеринария лабораторияләренең аккредитацияләүгә дәүләт ярдәменә финанслашыла торган чыгымнар»; |

с) юлны

| | |
|---|---|
| «23 0 01 R2610 | Мотор ягулыгы сыйфатында кысылган табигый газ тутыру инфраструктурасын төзү һәм үстерү  һәм мотор ягулыгы сыйфатында табигый газдан файдалану өчен автомобиль техникасын яңадан җиһазлау буенча проектларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «23 0 01 R2610 | Газ мотор ягулыгы базарын үстерү буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар»; |

т) юлны

| | |
|---|---|
| «36 0 01 R2610 | Мотор ягулыгы сыйфатында кысылган табигый газ тутыру инфраструктурасын төзү һәм үстерү  һәм мотор ягулыгы сыйфатында табигый газдан файдалану өчен автомобиль техникасын яңадан җиһазлау буенча проектларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «36 0 01 R2610 | Газ мотор ягулыгы базарын үстерү буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар»; |

у) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «37 К 00 00000 | «Татарстан Республикасында  физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» кече программасы» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «37 К 00 54450 | «Чаңгы һәм биатлон буенча күнегүләр һәм ярышлар үткәрү өчен спорт комплексы» капиталь төзелеш объектына капитал салуларга хәл ителгән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын каплау»; |

ф) юлны

| | |
|---|---|
| «38 3 Е8 54120 | Волонтерлыкка ярдәм итү буенча «Изге эшләр төбәге» Бөтенроссия иң яхшы төбәк практикалары конкурсын үткәрүгә финанслашыла торган чыгымнар |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

| | |
|---|---|
| «38 3 Е8 54120 | Волонтерлыкка ярдәм итү буенча «Изге эшләр төбәге» Бөтенроссия иң яхшы төбәк практикаларына  ярдәм итү һәм  ихтыярилыкны (волонтерлыкны) үстерү еллык конкурсын үткәрү йомгаклары буенча ихтыярилыкка (волонтерлыкка)  ярдәм итү практикаларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар»; |

х) юлны

| | |
|---|---|
| «99 0 00 72370 | «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 27 декабрь, 2004 ел, № 69-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, торакка хокукны тормышка ашыручы гаиләләргә һәр бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү максатыннан, махсус оешма булып торучы коммерциясез оешмага субсидияләр |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «99 0 00 72370 | «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 27 декабрь, 2004 ел, № 69-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, торакка хокукны тормышка ашыручы гаиләләргә һәр бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү максатыннан, махсус оешма булып торучы коммерциясез оешмага субсидияләр»; |

ц) юлны

| | |
|---|---|
| «99 0 00 95010 | Күп фатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь төзекләндерү үткәрүгә Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «99 0 00 95010 | Күп фатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь төзекләндерү үткәрүгә, Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар»; |

ч) юлны

| | |
|---|---|
| «99 0 00 R2990 | Дәүләт милкендәге хәрби каберлекләрне төзекләндерү һәм торгызу буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «99 0 00 R2990 | «2019 – 2024 елларга, Ватанны саклауда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү» федераль максатчан программасын тормышка ашыруга бәйле чараларны хәл кылуга финанслашыла торган чыгымнар»; |

ш) юлны

| | |
|---|---|
| «01 2 N1 55540 | Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәтләре белән тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «01 2 N1 55540 | Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәтләрен сатып алуларны тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар»; |

щ) юлны

| | |
|---|---|
| «01 Б 01 5849F | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясен |

йоктырган һәм (яки) инфекция йоктыруга шик төшкән затларга медицина ярдәме күрсәтүне финанс ягыннан өстәмә тәэмин итү»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «01 Б 01 5849F | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе буенча иминиятләштерелгән затларга, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясен (COVID-19) йоктырган һәм (яки) инфекция йоктыруга шик төшкән затларга медицина ярдәме күрсәтүне финанс ягыннан өстәмә тәэмин итү». |